ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 12.12.2025 1926 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы педагогик хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек эшчәнлеген тәэмин итә торган структураны һәм норматив актларны раслау турында» 2022 елның 30 мартындагы 385 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы һәм 2025 елның 5 ноябрендәге под-1761/25 боерыклары нигезендә, мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүматитехнологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы педагогик хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек эшчәнлеген тәэмин итә торган структураны һәм норматив актларны раслау турында» 2022 елның 30 мартындагы 385 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлегенең штат расписаниесенә үзгәрешләр кертеп, яңа редакциядә бәян итәргә (2 нче кушымта).

1.2. Муниципаль берәмлекнең педагогик хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә (3 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкчесе вазифаларын
башкаручы

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

А.А.Томилин

Татарстан Республикасы

Алабуга муниципаль районы

Башкарма комитеты

карарына 2 нче кушымта

**2025 елның 1 гыйнварыннан**

**«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең**
**ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ**

| **Атамасы вазифалары** | **Штатлар саны берәмлекләрдә** | **Вазифаи оклад** | **Оклад фонды аена (сумнарда)** |
|---|---|---|---|
| Идарә башлыгы урынбасары | **1** | **22 007** | **22 007** |
| **1. Мәгълүмат-методика бүлеге** | **14** | | **622 644,00** |
| Мәгълүмат-методик бүлек башлыгы | 1 | 49 380,00 | 49 380,00 |
| Өлкән методист | 1 | 44 107,20 | 44 107,20 |
| Методист (тәрбия эшләре буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| Методист (педагогларның һөнәри үсеше буенча) | 2 | 44 096,40 | 88 192,80 |
| Методист (табигый-математик цикл буенча) | 2 | 44 096,40 | 88 192,80 |
| Методист (гуманитар цикл буенча) | 2 | 44 096,40 | 88 192,80 |
| Методист (мәгариф системасын санлаштыру буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| Методист (милли белем буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| Методист (физкультура-эстетик цикл, технология һәм белем бирү пространствосының иминлеге буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| Методист (башлангыч белем бирү буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| Методист (мәктәпкәчә белем бирү буенча) | 1 | 44 096,40 | 44 096,40 |
| **2. Уку-укыту бүлеге** | **2** | | **40 120** |
| Бүлек башлыгы | 1 | 21 160 | 21 160 |
| Баш белгеч | 1 | 18 960 | 18 960 |
| **3. Мәктәпкәчә белем бирү бүлеге** | **3** | | **57 218** |
| Бүлек башлыгы | 1 | 21 160 | 21 160 |
| Баш белгеч | 1 | 18 960 | 18 960 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **4.Оештыру бүлеге** | 1 | 17 098 | 17 098 |
| Баш белгеч | **7,5** | | **157 138** |
| 1 категорияле белгеч | 4 | 17 098 | 68 392 |
| Белгеч | 0,5 | 16 928 | 8 464 |
| Машина йөртүче | 2 | 26 871 | 53 742 |
| Комплекслы хезмәт күрсәтү һәм бинаны ремонтлау буенча эшче | 1 | 26 540 | 26 540 |
| **БАРЛЫГЫ** | **27,5** | | **899 127,00** |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
3 нче кушымта

1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифаның исеме | Айга база окладының күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24 498 |
| | | | | |
| Дүртенче квалификация | Өлкән методист | - | - | 24 504 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәрәҗәсе | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек мөдире (башлыгы). | - | - | 24 598<br>24 690» |

2. Муниципаль берәмлекләрнең педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлекләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Советлар Социалистик Республикалары

берлегенең, Россия Советлар Федератив Социалистик Республикасының кызыксындыру характерындагы түләүләр күрсәтелә торган ведомство бүләкләренең ведомство бүләкләре» бүлегенең 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.9. пунктчасы белән тулындырырга:

| | |
|---|---|
| «1.9. | «Профессиягә тугрылык өчен» күкрәк билгесе».». |

Лист согласования к документу № 1926 от 12.12.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 12.12.2025 08:22

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Томилин А.А. | | Подписано 12.12.2025 - 11:13 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН